ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА НИЖНЕКАМСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07 02 2020 г. № 33

Түбән Кама шәһәренең муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестрын формалаштыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәсен раслау хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенең мәгълүмати ачыклыгын тәэмин итү, күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләрнең сыйфатын һәм һәркем өчен мөмкин булуын арттыру максатларында, карар бирәм:

1. Түбән Кама шәһәренең муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестрын формалаштыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәсен расларга (кушымта).

2. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны тәэмин итәргә һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җитәкче Д.И. Баландин

Татарстан Республикасы
Түбән Кама шәһәре башкарма комитетының
2020 елның 7-нче февраль
33-нче номерлы карары белән расланган
кушымта

Түбән Кама шәһәренең муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестрын
формалаштыру һәм алып бару турындагы
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

1. Әлеге Нигезләмә Түбән Кама шәһәренең муниципаль хезмәтләр күрсәтү реестрын формалаштыру һәм алып бару процессында (алга таба – текст буенча - Реестр) Башкарма комитетның структур бүлекчәләренең үзара хезмәттәшлеге процедурасын регламентлый.

2. Реестр җирле үзидарә органнары һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар эшчәнлегенең нәтиҗәлелегең арттыру, физик һәм юридик затларның муниципаль хезмәтләр турында хәбәрдарлыгын арттыру өчен алып барыла.

3. Реестрны формалаштыру Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлеге тарафыннан Башкарма комитет, шулай ук Башкарма комитет карамагындагы структур бүлекчәләр һәм учреждениеләр (алга таба – структур бүлекчәләр) тарафыннан билгеләнә торган хезмәт күрсәтү исемлеге нигезендә башкарыла.

4. Структур бүлекчәләр гамәлдәге норматив хокукый актлар нигезендә физик һәм юридик затларга күрсәтелә торган хезмәтләрнең исемлеген билгели.

5. Структур бүлекчәләр тарафыннан әзерләнгән муниципаль хезмәтләр исемлеге, Реестрны формалаштыру өчен, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының икътисади фаразлау, транспорт һәм элемтә бүлегенә (алга таба текст буенча – ИФТ һәм ЭБ тексты буенча) җибәрелә.

6. Реестр Башкарма комитетның муниципаль хокукый акты белән раслана. Реестр Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

7. Реестрны алып бару кәгазь һәм электрон чыганакларда башкарыла. Аңлашылмаучанлыклар килеп чыккан очракта, Реестрның кәгазьдә тәкъдим ителгән варианты өстенлекле санала.

8. Реестр муниципаль биремнәрне формалаштыру өчен учреждениеләр тарафыннан кулланыла. Реестрга кертелмәгән хезмәтләр күрсәтү буенча муниципаль биремнәрне планлаштыру һәм үтәү рөхсәт ителми.

9. Гамәлдәге хезмәтләр күрсәтүне гамәлдән чыгаруны (үзгәртүне) яки яңаларын гамәлгә кертүне күздә тоткан норматив хокукый актлар кабул ителгән очракта, структур бүлекчәләр Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының ИФТ һәм ЭБ нә Реестрга үзгәрешләр кертү кирәклеге турында язмача хәбәрнамә җибәрә. Хәбәрнамә үз эченә үзгәрешләрне нигезләүне һәм хезмәт күрсәтү турында мәгълүматны алырга тиеш.

10. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының ИФТ һәм ЭБ 5 эш көне дәвамында структур бүлекчәләрнең хәбәрнамәсен карый, шул исәптән

җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә керми торган хезмәтләр күрсәтү, хезмәтләр күрсәтүнең кабатлануын төшереп калдыруны тәэмин итә. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының ИФТ һәм ЭБ Реестрга үзгәрешләр кертү турында Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты проектын әзерли, баш тарткан очракта - нигезле бәяләмә.

11. Ел саен 15 апрельдән 15 майга кадәр структур бүлекчәләр, хезмәтләр күрсәтү һәм кулланучылар исемлеген төгәлләштерү, хезмәтләр күрсәтү формаларын оптимальләштерү өчен, Реестрга (ведомство карамагындагы хезмәтләр буенча) инвентарьлаштыру үткәрәләр. Инвентарьлаштыру нигезендә структур бүлекчәләр, кирәк булган очракта, Реестрга үзгәрешләр әзерләүне гамәлгә ашыралар.

12. Реестрга кертелгән үзгәрешләр Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.